ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**Постановление** **Карар**

02.11.2018 Казан ш. № 10-27/кс

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 1 декабрендәге 10-80/кс номерлы карары белән билгеләнгән «Эко-Сервис» Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2019 елга каты коммуналь калдыкларны күмүгә озакка исәпләнгән иң чик тарифларны корректировкалау турында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәяләр билгеләү турында» 2016 елның 30 маендагы 484 нчы карарына, Монополиягә каршы Федераль хезмәтнең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә көйләнелә торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы Нигезләмәгә ярашлы рәвештә, каты коммуналь калдыкларны күмүгә озакка исәпләнгән иң чик тарифларны 2019-2020 еллар өчен корректировкалау максатында Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2018-2020 елларга «Эко-Сервис» Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә иң чик тарифларны билгеләү турында» 2017 елның 1 декабрендәге 10-80/кс номерлы карарына түбәндәге үзгәртмәләрне кертергә:

1 нче Кушымтаны яңа редакциядә бирергә (теркәлгән);

2 нче Кушымтаны яңа редакциядә бирергә (теркәлгән);

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылган көннән соң 10 көн эчендә үз көченә керә.

Рәиснең беренче урынбасары А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының карарына
1 нче Кушымта
01.12.2017 № 10-80/кс
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитеты карары
редакциясендә
02.11.2018 № 10-27/кс)

«Эко-Сервис» Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте
тарафыннан күрсәтелә торган каты коммуналь калдыкларны күмүгә иң чик тарифлар,
2018-2020 елларга календарь бүленеш белән

| № п/п | Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә эшчәнлекнең көйләнелә торган төрләрен башкаручы оешмаларның, муниципаль берәмлекләрнең атамасы | Каты коммуналь калдыкларны күмүгә иң чик тарифлар, сум/куб.м | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2018 ел | | 2019 ел | | 2020 ел | |
| | | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән |
| | Кукмара муниципаль районы | | | | | | |
| 1 | «Эко-Сервис» Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 121,72 | 121,72 | 121,72 | 147,41 | 147,41 | 152,27 |

<*>Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланалар

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының карарына
2 нче Кушымта
01.12.2017 № 10-80/кс
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитеты карары
редакциясендә
02.11.2018 № 10-27/кс)

## 2018 – 2020 елларга «Эко-Сервис» Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелә торган каты коммуналь калдыкларны күмүгә иң чик тарифларны көйләүнең озакка исәпләнгән параметрлары

| № п/п | Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә эшчәнлекнең көйләнелә торган төрләрен башкаручы оешманың атамасы | Ел | Операцион чыгымнарның база дәрәҗәсе | Операцион чыгымнарның нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергия саклау һәм энергетик нәтиҗәлелек күрсәткечләре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | электр энергиясенең чагыштырма кулланылышы |
| | | | мең сум | % | % | кВт·сәг./куб.м |
| 1 | «Эко-Сервис» Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | |
| 1.1 | Каты коммуналь калдыкларны күмү | 2018 | 5073,02 | 1 | - | 0,16 |
| | | 2019 | 6214,29 | 1 | - | 0,16 |
| | | 2020 | 6361,32 | 1 | - | 0,16 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге